**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**муниципального**
**образования « Масягутовского**
**сельского поселения»**

ул.  Дружба д.12
с. Масягутово, Азнакаевский район, 423311
Тел ( Факс) : (8 – 85592) 38-2-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**“ Мэсгут авыл җирлеге”**
**муниципаль берэмлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Дружба урамы, йорт12, Мэсгут авылы,
Азнакай районы,423321
Тел(факс) :(8 –85592) 38-2-16

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«16» ноябрь  2021  ел　　　　№ 4

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Мәсгут  авылы Г. Багман ур. 2 нче йорттан  61 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче  этабын 2021 елның 26 ноябрендэ 10.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Мәсгут авылы Дружба  ур. 1 нче йорттан  55 нче йортка, 1 Май ур. 1, 3, 7, 14, 18, 24  нче йортка кадэр  теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендэ 12.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Мәсгут  авылы 8 Март  ур. 1 нче йорттан 59 нчы  йортка, 1 Май ур. 2, 4, 13, 16, 20, 26 нчы  йортка кадәр  теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2021 елның 26 ноябрендэ 14.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында ком-гравий катнашмаларыннан юлларны каплау;

- Азнакай районы Мәсгут авылында зират коймасын алыштыру (монтажлау, панель сатып алу);

- Азнакай районы Мәсгут авылында юлларны кардан чистарту;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында урамнарны яктырту өчен электр җиһазлары сатып алу;;

- Мәсгут авылында үзәкләштерелгән Чишмәдән эчә торган суга анализ;

- Азнакай районы Мәсгут авылында су җыю колонкалары сатып алу;;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык: Д.З. Миннеханов